**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

2024 елның 11 июне 49-РС номер

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе эшчәнлеге һәм 2023 елда Лаеш муниципаль районы территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү турында**

Лаеш муниципаль районында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе М. Г. Кузнецованың Лаеш муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе эшчәнлеге һәм 2023 елда Лаеш муниципаль районы территориясендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Лаеш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. 2023 елда Лаеш муниципаль районы буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе эшчәнлеге һәм Лаеш муниципаль районы территориясендә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен үтәү турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесенә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

3. Лаеш муниципаль районының һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына үз компетенциясе чикләрендә район халкын хокукый агарту максатларында эшне көчәйтүне тәкъдим итәргә:

Эшнең төрле рәвешләрен кулланып һәм массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итеп, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәҗрибәсеннән файдаланып, район халкының хокукый агарту һәм хокукый белемен үстерү мәсьәләләрендә халыкның төрле категорияләре белән актив хезмәттәшлек оештыруга юнәлтелгән чаралар күрергә.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**